# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Мамадыш муниципаль районы Соколка авыл җирлеге составына керүче Соколка торак пунктында үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

№ 1 «20» октябрь 2022 ел

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 нче статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ санлы Татарстан Республикасы законының 35 нче статьясы, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Соколка авыл җирлеге муниципаль берәмлеге» Уставының 23 статьясы, Мамадыш муниципаль районы Соколка авыл җирлегенең Соколка торак пунктында 2022 елның 20 октябрендә узган үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча түбәндәге сорау буенча гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә:

"Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Соколка авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан ветераннар, Бөек Ватан сугышында һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашканнарның тол хатыннары, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзалары, 2023 елда 600 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрү белән килешәсезме :

- насос сатып алу һәм Пионерская урамында су башнясы урнаштыру (бетон, арматура, торба, шланг, кабель һәм контракт буенча эш өчен түләү);
- агачларны кисү;
- урамнарны яктырту объектларына хезмәт күрсәтү (агымдагы ремонт, махсус җиһазларны сатып алу һәм алыштыру, килешү буенча эшләр өчен түләү);
- юлларны грейдлау, кардан чистарту (ягулык-майлау материаллары, трактор өчен запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү).

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 419 кеше кертелгән;

гражданнар җыенында тавыш бирүдә катнашучылар саны: 268 кеше, 64,0 % тәшкил итә:

Гражданнар җыенында катнашучыларның ачык тавыш бирү нәтиҗәләре түбәндәгечә бүленде:
«РИЗА» позициясе өчен 268 граждан тавыш бирде;
«КАРШЫ» позициясе өчен 0 граждан тавыш бирде;

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча Мамадыш муниципаль районы Соколка авыл җирлегенең Соколка торак пунктында узган гражданнар җыенын - уздырылган, нәтиҗәләре - дөрес, дип танырга.

2. Мамадыш муниципаль районы Соколка авыл җирлегенең Соколка торак пунктында түбәндәге сорау буенча узган гражданнар җыены карарын кабул ителгән дип танырга: "Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Соколка авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан ветераннар, Бөек Ватан сугышында һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашканнарның тол хатыннары, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзалары, 2023 елда 600 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрү белән килешәсезме :

- насос сатып алу һәм Пионерская урамында су башнясы урнаштыру (бетон, арматура, торба, шланг, кабель һәм контракт буенча эш өчен түләү);
- агачларны кисү;
- урамнарны яктырту объектларына хезмәт күрсәтү (агымдагы ремонт, махсус җиһазларны сатып алу һәм алыштыру, килешү буенча эшләр өчен түләү);
- юлларны грейдлау, кардан чистарту (ягулык-майлау материаллары, трактор өчен запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү).

3. Әлеге карарны Соколка авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Соколка авыл җирлеге башлыгына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Мамадыш муниципаль районы
Соколка авыл җирлеге Башлыгы,
Совет рәисе И.Р. Сафин